СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

24.06.2025 № 125

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының бишенче чакырылыш Наласа авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны “Арча хәбәрләре” (“Арский вестник”) газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) ул кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова